ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**04.03.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 537**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмаларның хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәяләү уздыру буенча иҗтимагый совет турында положениене раслау турында

“Россия Федерациясенең аерым закон актларына мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль саклау өлкәсендә оешмаларның хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү һәм федераль учреждениеләрнең медико-социаль экспертиза уздыруын камилләштерү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 5 декабрендәге 392нче-ФЗ федераль законга ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмаларның хезмәт күрсәтү сыйфатын арттыру максатыннан чыгып, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмаларның хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәяләү уздыру буенча Иҗтимагый совет турында беркетелгән Положениене расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый информация порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә кертелә.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
карары белән раслана
№537, 04.03.2019 ел

ПОЛОЖЕНИЕ
Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмаларның хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәяләү уздыру буенча Иҗтимагый совет турында

1. Гомуми положениеләр

1.1. Оешмаларның мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәяләү уздыру буенча Иҗтимагый совет (алда- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының киңәшче органы булып торып, Зеленодольск муниципаль районы гражданнарына мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмаларның хезмәт күрсәтү шартлары сыйфаты турында информация алырга, аларның эшчәнлеген камилләштерергә мөмкинлек бирә һәм шулай ук әлеге положениедә каралган башка вәкаләтләрне башкара.

1.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү буенча Иҗтимагый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституция законнарына, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм карарларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, муниципаль хокукый актларга һәм шулай ук әлеге положениегә нигезләнә.

1.3. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмаларның хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәяләү нәтиҗәләре һәм аларның эшчәнлеген яхшырту буенча тәкъдимнәр кертелгән карары, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар эшчәнлеген камилләштерү һәм аларның җитәкчеләренең эшчәнлеген бәяләү өчен, бирелгән һәм исәпкә куелган датасыннан алып бер ай эчендә каралырга тиеш.

1.4. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзалары үз эшчәнлекләрен җәмәгать башлангычында алып бара.

1.5. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы үз эшен гражданлык җәмгыяте институтлары, дәүләт властенең башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары, массакүләм информация чаралары вәкилләре белән үзара кызыксыну нигезендә алып бара.

1.6. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы эшчәнлеге турында мәгълүмат Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең (алда – «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырыла: http://zelenodolsk.tatarstan.ru

1.7. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый совет Положениесе күрсәтелгән Иҗтимагый советны оештырган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

2. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының максатлары, бурычлары һәм вәкаләтләре

2.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы эшчәнлегенең төп максатлары булып тора:
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан мәдәният һәм мәгариф муниципаль оешмаларының һәм муниципаль берәмлек бюджеты бюджет ассигнованиеләре исәбенә мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтә торган башка оешмаларның хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатына җәмәгать контролен көчәйтү;
- ярашлы өлкәдә ачыклык, законлылык һәм профессионализм принципларын үстерү.

2.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының бурычлары булып тора:
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмаларның хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәяләү уздыру;
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларын кабул иткәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмы;
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмаларның хезмәт күрсәтү шартлары сыйфаты турында җәмәгатьчелекне мәгълүматлаштыруны арттыру.

2.3. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советына йөкләнгән бурычлар кысасында:
-сыйфатка бәйсез бәяләү уздырыла торган оешмаларның исемлеген раслый;
-мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмаларның хезмәт күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүмат җыйган һәм туплаган оешмалар (алда – оператор) белән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты төзегән эшләр, хезмәтләр сатып алу турында документация проектларын һәм шулай ук муниципаль контрактлар проектларын карауда катнаша;
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмаларның хезмәт күрсәтү шартларына бәйсез сыйфат бәяләвен оператор күрсәткән мәгълүматны исәпкә алып башкара;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмаларның хезмәт күрсәтү шартларына бәйсез сыйфат бәяләве уздыру нәтиҗәләрен һәм шулай ук аларның эшчәнлеген яхшырту турында тәкъдимнәрен бирә.

3. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы составы:

3.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый советы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты мөрәҗәгате буенча, күрсәтелгән мөрәҗәгать килгән көннән алып бер ай эчендә сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советын төзи һәм аның составын раслый.

3.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы гражданнарның, инвалидларның җәмәгать берләшмәләре хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау максатыннан оешкан җәмәгать оешмалары вәкилләреннән төзелә.

3.3. Күрсәтелгән Иҗтимагый совет тарафыннан мәдәният һәм мәгариф муниципаль оешмаларының һәм муниципаль берәмлек бюджеты бюджет ассигнованиеләре исәбенә мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә хезмәт күрсәтүче башка оешмаларның хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәяләү ясала.

3.4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый советы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетын аның органнарында оештырылган сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы составы турында хәбәр итә.

3.5. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы составы расланган көннән алып 30 календарь көннән соңга калмыйча сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының беренче утырышын уздыруны оештыра һәм анда аның әгъзалары арасыннан сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының рәисе һәм рәис

урынбасары сайлана. Карар сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының барлык әгъзалары ачык тавыш биреп, күпчелек тавыш җыю юлы белән чыгарыла.

3.6. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының рәисен яисә рәис урынбасарын вазифадан азат итү турындагы мәсьәлә сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе, Татарстан Республикасы муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе мөрәҗәгате һәм шулай ук сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисенең яисә рәисе урынбасарының шәхси гаризасы яисә сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзаларының биштән бер өлешеннән торган төркеме тәкъдиме буенча карала. Карар сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзалары гомуми санынннан чыгып, иң күп тавыш бирү юлы белән чыгарыла.

3.7. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзалары арасыннан сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы сәркатибен билгели.

3.8. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы составы өч ел срокка раслана.

Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советын яңа срокка билгеләгәндә аның составының өчтән бер өлеше алмаштырыла.

3.9. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы составына түбәндәге вәкилләр керә алмый:

- дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнары;
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып бара торган җәмәгать берләшмәләре;
- мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып бара торган оешмалар җитәкчеләре (аларның урынбасарлары) һәм хезмәткәрләре.

3.10. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы үз эшенә шундый бәяләү нәтиҗәләрен карау һәм төзү өчен мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып бара торган җәмәгать берләшмәләре һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы вәкилләрен җәлеп итә.

3.11. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзалары саны биш кешедән дә ким булмаска тиеш.

3.12. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзасы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы карарына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе тәкъдиме белән түбәндәге очракларда туктатыла:

- Россия Федерациясе җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаепләнгәндә;
- аңа административ арест буларак җинаять җаваплылыгы билгеләнгәндә;
- ул законнар чыгару (вәкаләтле) дәүләт власте органына депутатлыкка кандидат, җирле үзидарә органында сайлау вазифасына кандидат, сәяси партия кандидатының вәкаләтле вәкиле яисә ышанычлы кешесе булып теркәлгәндә һәм шулай ук Россия Федерациясендә референдум уздыру буенча инициатива төркеме составына кергән очракта.

3.13. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

- аның вәкаләтләренең срогы чыкса;
- ул сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы составыннан чыгуы турында гариза бирсә;
- ул сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы эшендә сәламәтлек торышы буенча катнаша алмаса;
- аңа карата чыгарылган суд карары үз көченә кертелсә;
- законлы көченә кертелгән суд карары нигезендә ул эшкә сәләтсез дип танылса яисә билгесез сәбәп белән ул анда катнашмаса;

- этик нормаларны тупас бозса - сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителгән сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы карары белән;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларында системалы рәвештә бер сәбәпсез катнашмаса (өч тапкырдан артык) – сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителгән сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы карары буенча;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисенең яисә урынбасарының күрсәтмәләрен бер сәбәпсезгә системалы үтәмәсә (ике тапкырдан күбрәк) - сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителгән сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы карары буенча;
- ул Россия Федерациясе дәүләт вазифасына, Россия Федерациясе дәүләт гражданлык вазифасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазифасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларына дәүләт гражданлык хезмәте вазифасына, муниципаль вазифага яисә муниципаль хезмәт вазифасына билгеләнсә;
- ике гражданлык алса;
- Россия Федерациясе гражданины булудан туктаса.

3.14. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзасы вәкаләтләрен туктату Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый советы рәисе карарына ярашлы рәвештә сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзасының язма гаризасы яисә сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе яисә урынбасары күрсәтмәсе нигезендә һәм шулай әлеге положениенең 3.13нче пунктында каралганнар ачыкланганда алып барыла.

## 4. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзасы түбәндәге хокукларга ия:
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты инициативасы белән уздырылган, дәүләт сере булып торган информацияләр, шәхси мәгълүматларга кагылышлы белешмәләр һәм информацияне бирергә ярамаган мәгълүматлар кулланылуга бәйле федераль законнарга ярашлы чикләнгән чаралардан тыш, мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә эшчәнлек алып барган оешмаларның эшчәнлегенә кагылган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, «түгәрәк өстәлләрдә» һәм башкаларда) катнаша ала;
- инициатив тәртиптә сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советына аналитик язмалар, докладлар һәм башка информацион-аналитик материаллар әзерләргә һәм җибәрергә;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе аша сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы эш планына тәкъдимнәр һәм аның утырышларын уздыру тәртибен кертергә;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышлары көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне карауда катнашу өчен чакырылган затлар кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзалыгыннан чыгарга.

4.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзасы бурычлы:
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе кушкан күрсәтмәләрне үтәргә;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы эш тәртибен әлеге типовой положениедә каралганча белергә һәм сакларга;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларында шәхси үзенә катнашырга;

- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы үзенә куелган бурычларны үтәү өчен оештырылган экспертлар, эш төркемнәре, комиссияләр һәм башка эшче органнар эшендә катнашырга.

5. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының эш тәртибе

5.1. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы үз эшен сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларында расланган планнарга һәм программаларга ярашлы рәвештә сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе күрсәтмәсе буенча оештыра.

5.2. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы эшен планлаштыру сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзалары, сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тәкъдимнәре нигезендә алып бара.

5.3. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышлары кварталга бер тапкырдан ким булмаган кадәр санда уздырыла. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән ныгытыла.

5.4. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышлары сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының яртысыннан да ким булмаган әгъзасы катнашканда дөрес булып исәпләнә. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзасы утырышта шәхси үзе катнаша алмаганда көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча үз хокукын һәм фикерен язма рәвештә, факсимиль яисә электрон почта аша сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының башка әгъзасына, бу хакта сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисен яисә аның урынбасарын, яисә сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының җаваплы сәркатибен алдан ук кисәтеп куеп, бирә ала. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларында катнашучылар исәбенә сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының башка әгъзаларына үз тавышын ышанып тапшырган сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының әгъзалары өстәлә.

Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

5.5. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларын бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе, ә ул булмаганда сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе урынбасары уздыра.

5.6. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе:

- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне алып бара;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларын алып бара;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының эш планын әзерли һәм шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны раслауга сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советына бирә;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларын оештыра;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышының көн тәртибен раслый;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы тәкъдимнәренә, беркетмәләргә һәм башка документларга кул куя;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларын уздыруның вакытын һәм урынын билгели;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы үз эшчәнлеге кысасында йөкләнгән бурычлары һәм максатлары буенча сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзаларына порученииеләрен бирә;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы исеменнән запросларга, тәкъдимнәргә, җавапларга, аңлатмаларга һәм мөрәҗәгатьләргә кул куя;

- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле башка функцияләрне башкара.

5.7. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе урынбасары:

- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе рәсми рәвештә булмаганда аның функцияләрен башкара;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларын әзерли;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышлары көн тәртибен раслый һәм аны сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисенә раслауга бирә;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе кушуы буенча сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы эшчәнлеге өчен кирәкле башка функцияләрне үти.

5.8. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының җаваплы сәркатибе:

- утырышларга материаллар һәм карарлар проектларын әзерләүне оештыра;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзаларына сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышының уздырылу вакыты һәм урыны турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмат-белешмә материаллары белән тәэмин итә;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советын һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән үзара элемтәдә торуын тәэмин итә;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы эшчәнлеген документаль-техник тәэмин итүне башкара;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларының беркетмәләрен төзи һәм кабул ителгән карарлар үтәлешен контрольдә тота;
- сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларының көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.9. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзалары сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышында тыңланырга тиешле мәсьәләләрне әзерләү өчен сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе урынбасары белән килештереп, эшче, эксперт төркемнәренә һәм башка эш органнарына берләшә һәм сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы составына кермәгән белгечләрне материаллар әзерләүгә җәлеп итә ала.

5.10. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы карары буенча сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларына Иҗтимагый совет караган сорауларга тиешле нәтиҗә яисә белешмә бирү өчен башкарма органнар, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре һәм башка белгечләр чакырылырга мөмкин. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы әгъзасы булмаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышларында сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы чакыруы буенча катнаша ала.

5.11. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советына кертелгән материаллар сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе урынбасарына сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы утырышы билгеләнгән датадан ун календарь көннән соңга калмыйча бирелергә тиеш. Материалларны билгеләнгән срогыннан соңга калып бирү сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советы рәисе яисә урынбасары белән килештерелә.

5.12. Сыйфатны бәйсез бәяләү Иҗтимагый советының оештыру-техник эшчәнлеген Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты алып бара.